КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 18 октябрь г.Казань № 933

Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу өчен федераль вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган субвенцияләрне тоту тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип тану турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу буенча федераль вәкаләтләрне үтәү өчен федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына һәм Байконур шәһәре бюджетына субвенцияләр бирү кагыйдәләрен раслау турында» 2005 ел, 28 март, 159 нче карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу өчен федераль вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган субвенцияләрне тоту тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«2006 елда гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны компенсацияләүрнең федераль фондыннан керә торган субвенцияләр исәбеннән финанслау тәртибе турында» 2006 ел, 1 март, 92 нче;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2006 елда гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны компенсацияләүнең федераль фондыннан керә торган субвенцияләр исәбеннән финанслау тәртибе турында» 2006 ел, 1 март, 92 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 ел, 16 февраль, 50 нче.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Гражданлык хәле актларын язу идарәсенә һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин